| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>10 июля 2015 года | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>№549 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында

“Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе” МБУ җитәкче урынбасары П.Н.Сергеевның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Осиново авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары” Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы нигезендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә расларга (карта һәм текст нигезләмәсе бирелә).

2.Зеленодольск муниципаль районы Осиново авыл җирлеге Советына, әлеге карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, үз муниципаль хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны аның кушымталары белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре порталы составы сайтында( http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (fgis.tp) әлеге карар кабул ителгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Зеленодольск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**